**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2021 елның 17 мае №33

Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын тану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Яшел Үзән муниципаль районы составына керүче «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милек белән идарә итү, аннан файдалану, җир кишәрлекләре белән эш итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыруга бәйле рәвештә, «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында, Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында" 2016 елның 27 июнендәге 34 номерлы карары»;

- 2017 елның 19 декабрендәге 92 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 июнендәге «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында»гы 34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары»;

- 2019 елның 22 июлендәге 153 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2016 елның 27 июнендәге 34 номерлы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр

кертү хакында» (2017 елның 19 декабрендәге 92 номерлы үзгәрешләр белән))»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo. порталында урнаштыру tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы).

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Рус Әҗиле**
**авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **Г. Ф. Семахина**